**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 сентября 2015 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 августа 2009 года № 43-ЗРТ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (III часть); 2011, № 4 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 4 (I часть); 2015, № 4) следующие изменения:

1) в пункте 13 статьи 11 слова «транспортными средствами, осуществляющими перевозки тяжеловесных грузов,» заменить словами «тяжеловесными транспортными средствами», слова «общего пользования» исключить;

2) в статье 13:

а) в пункте 8 слова «транспортных средств, осуществляющих перевозки опасных, тяжеловесных и (или) крупногабаритных грузов» заменить словами «тяжеловесных и (или) крупногабаритных транспортных средств»;

б) в пункте 9 слова «транспортными средствами, осуществляющими перевозки тяжеловесных грузов,» заменить словами «тяжеловесными транспортными средствами», слова «общего пользования» исключить;

3) статью 28 изложить в следующей редакции:

«Статья 28. **Движение по автомобильным дорогам тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства**

1. Движение по автомобильным дорогам крупногабаритного транспортного средства, а также тяжеловесного транспортного средства, масса которого с грузом или без груза и (или) нагрузка на ось которого более чем на два процента

превышают допустимую массу транспортного средства и (или) допустимую нагрузку на ось, допускается при наличии специального разрешения, выдаваемого в порядке, установленном статьей 31 Федерального закона.

2. Выдача специального разрешения, указанного в части 1 настоящей статьи, осуществляется:

1) уполномоченным органом самостоятельно либо через уполномоченные им подведомственные организации в случае, если маршрут, часть маршрута тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства проходят по автомобильным дорогам регионального значения, участкам таких автомобильных дорог, по автомобильным дорогам местного значения, расположенным на территориях двух и более муниципальных образований (муниципальных районов, городских округов), при условии, что маршрут указанного транспортного средства проходит в границах Республики Татарстан и маршрут, часть маршрута не проходят по автомобильным дорогам федерального значения, участкам таких автомобильных дорог;

2) органом местного самоуправления муниципального района самостоятельно либо через уполномоченную им подведомственную организацию в случае, если маршрут, часть маршрута тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства проходят по автомобильным дорогам местного значения муниципального района, по автомобильным дорогам местного значения, расположенным на территориях двух и более поселений в границах муниципального района, и не проходят по автомобильным дорогам федерального, регионального значения, участкам таких автомобильных дорог;

3) органом местного самоуправления поселения самостоятельно либо через уполномоченную им подведомственную организацию в случае, если маршрут, часть маршрута тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства проходят по автомобильным дорогам местного значения поселения, при условии, что маршрут указанного транспортного средства проходит в границах этого поселения и маршрут, часть маршрута не проходят по автомобильным дорогам федерального, регионального, местного значения муниципального района, участкам таких автомобильных дорог;

4) органом местного самоуправления городского округа самостоятельно либо через уполномоченную им подведомственную организацию в случае, если маршрут, часть маршрута тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства проходят по автомобильным дорогам местного значения городского округа и не проходят по автомобильным дорогам федерального, регионального значения, участкам таких автомобильных дорог;

5) собственником автомобильной дороги в случае, если маршрут тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства проходит по частной автомобильной дороге.

3. В случаях, предусмотренных пунктами 1 – 4 части 2 настоящей статьи, за выдачу специального разрешения, указанного в части 1 настоящей статьи, уплачивается государственная пошлина в соответствии с законодательством Российской Федерации о налогах и сборах.

4. Орган, осуществляющий выдачу специального разрешения, указанного в части 1 настоящей статьи, согласовывает маршрут тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства с владельцами автомобильных дорог, по которым проходит такой маршрут, а в случае превышения установленных Правительством Российской Федерации допустимых габаритов более чем на два процента – и с соответствующими подразделениями федерального органа исполнительной власти, уполномоченного осуществлять контрольные, надзорные и разрешительные функции в области обеспечения безопасности дорожного движения. В случаях, если для движения тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства требуется укрепление отдельных участков автомобильных дорог или принятие специальных мер по обустройству автомобильных дорог и пересекающих их сооружений, инженерных коммуникаций в пределах согласованного маршрута, проводится согласование с соответствующими подразделениями федерального органа исполнительной власти, уполномоченного осуществлять контрольные, надзорные и разрешительные функции в области обеспечения безопасности дорожного движения. Допускается установление постоянных маршрутов тяжеловесных и (или) крупногабаритных транспортных средств. Взимание платы за согласование маршрута тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства не допускается.

5. Владельцы тяжеловесных транспортных средств возмещают вред, который будет причинен таким транспортным средством, в порядке, установленном в соответствии с Федеральным законом.

6. В случае, если для движения тяжеловесного и (или) крупногабаритного транспортного средства требуется оценка технического состояния автомобильных дорог, их укрепление или принятие специальных мер по обустройству автомобильных дорог, их участков, а также пересекающих автомобильную дорогу сооружений и инженерных коммуникаций, лицо, в интересах которого осуществляются перевозки указанным транспортным средством, возмещает юридическим лицам и индивидуальным предпринимателям, осуществляющим такую оценку и принимающим такие меры, расходы на осуществление такой оценки и принятие таких мер до получения специального разрешения, указанного в части 1 настоящей статьи.

7. В случае, если нагрузка на ось тяжеловесного транспортного средства превышает допустимую нагрузку на ось транспортного средства более чем на два процента, но не более чем на 10 процентов, специальное разрешение на движение такого транспортного средства по установленному постоянному маршруту, в том числе в электронной форме, выдается в упрощенном порядке. Уполномоченный орган, собственник частной автомобильной дороги, осуществляющие выдачу указанного специального разрешения в упрощенном порядке, доводят до заявителя размер платы в счет возмещения вреда, причиняемого тяжеловесным транспортным средством, в течение одного рабочего дня со дня регистрации заявления о выдаче указанного специального разрешения.

8. Основанием для установления постоянного маршрута, указанного в части 7 настоящей статьи, являются выданные в течение предыдущих 12 месяцев

специальные разрешения на движение тяжеловесных транспортных средств с превышением допустимых нагрузок на ось на 10 процентов и более.

9. Перечни постоянных маршрутов, установленных уполномоченным органом и органами местного самоуправления, указанными в части 2 настоящей статьи, размещаются на официальных сайтах указанных органов в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

10. Специальное разрешение должно быть выдано в срок не более одного дня со дня подтверждения внесения платы в счет возмещения вреда, причиняемого тяжеловесным транспортным средством.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования, за исключением абзацев четырнадцатого – семнадцатого пункта 3 статьи 1 настоящего Закона.

2. Абзацы четырнадцатый – семнадцатый пункта 3 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2018 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
9 октября 2015 года
№ 81-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның 13 пунктында “гомуми файдаланудагы” сүзләрен төшереп калдырырга, “авыр йөк ташый торган транспорт чаралары” сүзләрен “авыр йөкле транспорт чаралары” сүзләренә алмаштырырга;

2) 13 статьяда:

а) 8 пунктта “куркыныч, авыр һәм (яисә) эре габаритлы йөкләр ташый торган транспорт чаралары” сүзләрен “авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чаралары” сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта “гомуми файдаланудагы” сүзләрен төшереп калдырырга, “авыр йөк ташый торган транспорт чаралары” сүзләрен “авыр йөкле транспорт чаралары” сүзләренә алмаштырырга;

3) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“28 статья. **Автомобиль юллары буйлап авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте**

1. Автомобиль юллары буйлап эре габаритлы транспорт чарасы, шулай ук массасы йөк белән яисә йөксез һәм (яисә) күчәренә йөкләнеше транспорт чарасының рөхсәт ителә торган массасыннан һәм (яисә) күчәргә рөхсәт ителә

торган йөкләнештән ике проценттан артык булган авыр йөкле транспорт чарасы хәрәкәте Федераль законның 31 статьясында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган махсус рөхсәт булганда рөхсәт ителә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус рөхсәт бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) вәкаләтле органның үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан – авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше региональ әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап, ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләр (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган очракта, күрсәтелгән транспорт чарасы маршруты Татарстан Республикасы чикләрендә узу һәм маршрут, маршрут өлеше федераль әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмау шарты белән;

2) муниципаль районның җирле үзидарә органының үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан – авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап, муниципаль район чикләрендәге ике һәм аннан да күбрәк җирлекләр территорияләрендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган һәм федераль, региональ әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмаган очракта;

3) җирлекнең җирле үзидарә органының үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан – авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше җирлекнең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган очракта, күрсәтелгән транспорт чарасы маршруты шушы җирлек чикләрендә узу һәм маршрут, маршрут өлеше муниципаль районның федераль, региональ, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмау шарты белән;

4) шәһәр округының җирле үзидарә органының үзе йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан – авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты, маршруты өлеше шәһәр округының җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап узган һәм федераль, региональ әһәмияттәге автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының участоклары буйлап узмаган очракта;

5) автомобиль юлы милекчесе тарафыннан – авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршруты хосусый автомобиль юлы буйлап узган очракта.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 – 4 пунктларында каралган очракларда әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус рөхсәт бирган өчен салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт пошлинасы түләнә.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршрутын мондый маршрут уза торган автомобиль юллары хуҗалары белән, ә Россия

Федерациясе хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рөхсәт ителгән габаритлар ике проценттан арткан очракта, федераль башкарма хакимиятнең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге тикшереп тору, күзәтчелек һәм рөхсәт бирү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының тиешле бүлекчәләре белән дә килештерә. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте өчен автомобиль юлларының аерым участокларын ныгыту яисә килештерелгән маршрут чикләрендә автомобиль юлларын һәм алар белән кисешә торган корылмаларны, инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү таләп ителгән очракларда, федераль башкарма хакимиятнең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге тикшереп тору, күзәтчелек һәм рөхсәт бирү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының тиешле бүлекчәләре белән килештерү үткәрелә. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чараларының даими маршрутларын билгеләү рөхсәт ителә. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы маршрутын килештергән өчен түләү алу рөхсәт ителми.

5. Авыр йөкле транспорт чаралары хуҗалары мондый транспорт чарасы китерәчәк зыянны Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә каплыйлар.

6. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте өчен автомобиль юлларының техник торышын бәяләү, аларны ныгыту яисә автомобиль юлларын, аларның участокларын, шулай ук автомобиль юлы белән кисешә торган корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү таләп ителгән очракларда, үз мәнфәгатьләрендә күрсәтелгән транспорт чарасында ташулар гамәлгә ашырыла торган зат, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган махсус рөхсәт алганчы, мондый бәяләүне гамәлгә ашыручы һәм шушы чараларны күрүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга әлеге бәяләүне гамәлгә ашыру һәм мондый чараларны күрү чыгымнарын каплый.

7. Авыр йөкле транспорт чарасы күчәренә йөкләнеш транспорт чарасы күчәренә рөхсәт ителә торган йөкләнештән ике проценттан арткан, ләкин 10 проценттан артмаган очракта, мондый транспорт чарасының билгеләнгән даими маршрут буенча хәрәкәтенә махсус рөхсәт, шул исәптән электрон рәвештә дә, гадиләштерелгән тәртиптә бирелә. Күрсәтелгән махсус рөхсәтне гадиләштерелгән тәртиптә бирүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган, хосусый автомобиль юлы милекчесе әлеге махсус рөхсәтне бирү турындагы гариза теркәлгән көннән бер эш көне дәвамында мөрәҗәгать итүчегә авыр йөкле транспорт чарасы китерә торган зыянны каплау хисабына түләү күләмен җиткерәләр.

8. Әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән даими маршрутны билгеләү өчен нигез булып күчәргә рөхсәт ителә торган йөкләнешләрдән 10 проценттан һәм аннан артык булган авыр йөкле транспорт чарасы хәрәкәтенә алдагы 12 ай эчендә бирелгән махсус рөхсәтләр тора.

9. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтле орган һәм җирле үзидарә органнары билгеләгән даими маршрутлар исемлекләре күрсәтелгән органнарның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

10. Махсус рөхсәт авыр йөкле транспорт чарасы китерә торган зыянны каплау хисабына түләү кертү расланган көннән бер көннән дә артык булмаган вакытта бирелергә тиеш.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы Законның 1 статьясындагы 3 пунктының ундүртенче – унҗиденче абзацларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының ундүртенче – унҗиденче абзацлары 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 81-ТРЗ